“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе”
дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе

Педагогик
киңәшмә утырышында каралды
“29”август 2022 ел. №1
Интернат мәктәбе директоры
_______________Л.Р.Мартынова
Боерык белән кертелде №98-0
“ 31 ” 08 2022 ел

**8нче ГОМУМБЕЛЕМБИРҮ** сыйныфы өчен
**туган (татар) теленнән уку предметы буенча**
**эш программасы**
Атнага **1** сәгать, елга **35_** сәгать

Төзүчесе:
**татар теле һәм әдәбият укытучысы Мөхәммәтҗанова Л.Ф.**

Килешенгән:
Директор урынбасары________И.Б.Шарифуллина

МБ утырышында каралды, беркетмә№1 “26 ”август 2022 ел
МБ җитәкчесе ___________М.Г.Шәрипова

Әлмәт 2022 ел

# Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге **документларны** исәпкә алып төзелде:

**Эш программасы статусы.**

1. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Законы (21.12.2012, №273-ФЗ)
2. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы Законы (25.10.1991, №1807-1, ред.12.03.2014)
3. Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы боерыгы 5.03.2004 №1089.
4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Инвалид балаларны өйдә тәрбияләү һәм укыту тәртибе һәм инвалидларның белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында" 16.06. 2008 ел, 401 нче карары.
5. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (22.07.2013, № 68-ЗРТ)
6. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (8.07.1992, №1560-XII; ред. 12.06.2014№53-ЗРТ)
7. Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы(1 — 11 нче сыйныфлар) /Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Казан:2018
8. Әлмәт интернат мәктәбендә дисциплина, предмет, уку курсларының эш программалары раслануы, эшләү тәртибе, структура нигезләмәсе 31.08.22 № 98-О.
9. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына программасы.
10. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына базислы уку-укыту планы.
11. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына эш программасы турында нигезләмә (локальный акт).

- Үрнәк программа: Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы. Төп гомуми белем бирү мәктәбе / Төзүче-авторлар: Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова. – Казан, 2013. (http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263450.docx).
- Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1-11 нче сыйныфлар)/ Төзүче-авторлар: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева. – Казан, 2014. (http://mon.tatarstan.ru/rus/programmy.htm?page=2)

Эш программасы түбәндәге **дәреслек** буенча укыту өчен эшләнде:

Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. “Күңелле татар теле”. 8 нче сыйныф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). - Казан: "Татармультфильм" нәшрияты, 2015.

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – системалы-эшчәнлекле (системно-деятельностный подход) юнәлеш, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да карый. Рус телле балаларга татар теле укыту системасының барлык компонентлары да: программалар, укыту-методик комплектлары, укыту процессы, белем дәрәҗәсенә контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – бар да бер максатка – нәтиҗәгә хезмәт итә. Эш программасы коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын исәпкә алып төзелде.

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен укыту **максатлары** берничә аспектны үз эченә ала: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

***Танып белү максатының эчтәлеге***

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

***Үстерү максатының эчтәлеге***

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Бу максатлар программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда да беренче планга куела.

***Тәрбияви максатның эчтәлеге***

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Татар теленең грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика, грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

***Белем бирү максатының эчтәлеге***

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

## Предметның гомуми тасвирламасы

**“Филология”** телнең билгеләр системасын өйрәнгән, кешелекнең аралашу нигезендә яткан һәм гражданлык, этник, социаль тәңгәллекне формалаштырган, аңларга һәм аңлатырга мөмкинлек тудырган, кешенең эчке халәтен чагылдырырга ярдәм иткән өлкә буларак түбәндәгеләрне тәэмин итә:

− әдәби мирас һәм аның аша туган тел, дөнья мәдәнияте хәзинәләре, цивилизация казанышларын файдалану мөмкинлегенә ия булу;

− төрле мәдәниятләрнең үзенчәлекләрен аңлау өчен нигез хәзерләү һәм аларга хөрмәт тәрбияләү;

− рухи, әхлакый, эмоциональ, иҗади, этик һәм танып белү үсешенә тәэсир иткән интеллектуаль һәм социаль үсеш арасындагы бәйләнешне аңлау;

− билингвизмны күздә тотып, телләрне өйрәнүне күз алдында торткан төп күнекмәләрне формалаштыру;

− башка уку-укыту предметларын үзләштерүдә югары нәтиҗәләргә ирешү өчен актив һәм потенциаль сүзлек запасын баету.

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Татар теле буенча эш программасы яңа темаларны нәтиҗәле үзләштерүне күздә тота. Моның өчен уку елы башында һәм ахырында кабатлауга зур игътибар бирелә. Һәр тема үткән материалны кабатлау, контроль эшләр, сүзлек диктантлары, изложениеләр, бәйләнешле сөйләм үстерү, тыңлап һәм укып аңлау белән тәмамлана.

Укучыларның сүзлек запасын баету өчен сүзлекләр белән эшләү даими алып барыла. Сүзлекләр белән эшләүнең иң мөһим таләбе - укучыларның таныш булмаган сүзләрне күрә, сүзлекләргә мөрәҗәгать итә һәм аларны куллана белергә өйрәтү. Татар теле буенча эш программасы укучыларның татар телендә сөйләшүчеләр белән язмача аралашу күнекмәләре булдыруга да юнәлтә.

**Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләр (5-10 нчы сыйныфлар)**

**Тыңлап аңлау**

–Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

–сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

–зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

–Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

**Диалогик сөйләм**

–Сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

–аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

–парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

–терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

–татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

**Монологик сөйләм**

–Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

–конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

–монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

–өйрәнгән текстны үз сүзләреӊ белән сөйләп бирә белү;

–өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

**Уку**

–Уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

–текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

–таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

–таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

**Язу**

–Өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;

–конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

–прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;

–үзеңне борчыган проблемага карата үз фикерләреңне язмача җиткерә белү;

–тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

**Укучылар үзләштерергә тиешле грамматик материал**

1. Хикәя фигыльнең заман формаларын (хәзерге, үткән, киләчәк) сөйләмдә куллануны ныгыту.
2. Сан төркемчәләрен гомумиләштереп кабатлау.
3. Билгеләү, билгесезлек, юклык, тартым алмашлыкларының сөйләмдә еш кулланыла торган очраклары белән таныштыру.
4. Сыйфат фигыльнең барлыкта һәм юклыкта заман формаларын сөйләмдә куллану.
5. Хәл фигыльне сөйләмдә куллану.
6. Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллану.
7. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне сөйләмдә куллану.
8. Гади фигыль хәбәрле (Мин татарча беләм), исем хәбәрле (Безнең гаиләбез тату) һәм тезмә фигыль хәбәрле (Мин укырга яратам) гади җөмләне таный, аера белү.
9. Тиңдәш кисәкле җөмләләрне таный, аера белү.

| № | Дәрес темасы | Уку-укыту эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| 1 | С Новым учебным годом!<br><br>Яңа уку елы котлы булсын! | 4-5 нче бит: 1-4 нче күнегү. Монологик һәм диалогик сөйләм, тыңлау, сүзлек белән эш, китап белән эш, тәрҗемә эше. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Укытучыларны, укучыларны, дусларны бәйрәм белән котлый, бер-береңә комплиментлар әйтә белү. Л: котлыйм, уңышлар, сәламәтлек, кәеф, сагына, өйрәнә, тарата, таныша, бурычлы. | 1.09 | |
| 2 | Повторение окончаний принадлежности у существительных.<br><br>Исемнәрнең тартым белән төрләнешен кабатлау. | 5-6 нчы бит: 5-7 нче күнегү. Монологик һәм диалогик сөйләм, тыңлау, сүзлек белән эш, китап белән эш, тәрҗемә эше. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Тартымлы исемнәрне сөйләмдә дөрес куллану. Г: тартык һәм сузык авазларга беткән исемнәрнең тартым белән төрләнеше, -мы/-ме сорау кисәкчәсе, хикәя һәм сорау җөмләдә сүз тәртибе. | 8.09 | |
| 3 | Лексико-грамматический материал в стихотворении Р.Валиева “Моя школа”.<br><br>Р.Вәлиева “Мәктәбем” шигырендәге лексик-грамматик материал. | 6-7 нче бит: 8-11 нче күнегү. Сәнгатьле уку. Монологик һәм диалогик сөйләм, тыңлау, сүзлек белән эш, китап белән эш, тәрҗемә эше. Ишетеп аңлау күнегүләре. | “Мәктәбем” шигырен сәнгатьле уку. Мәктәбең турында сөйли белү. Тексттагы тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү. Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү. | 15.09 | |
| 4 | Расписание уроков по дням недели.<br><br>Атна көннәрендә дәресләр расписаниесе. | 8-9 нчы бит: 1-5 нче күнегү. Атна көннәрендә дәресләр расписаниесе төзү. “Беренче сентябрь» тексты буенча эш күнегүләре. Сөйләү. Сүз төркемнәрен кабатлау. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Атна көннәре атамаларын кулланып, нишләгәнеңне, нишләячәгеңне, расписание буенча нинди фәннәр керәчәген сөйли белү. Л: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе. Г: сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, рәвеш. | 22.09 | |
| 5 | Спряжение глаголов изъявительного наклонения прошедшего времени.<br><br>Үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 12-13 нче бит: 3-4 нче күнегү. Хаталар өстендә эшләү. Диалог төзү. Тәрҗемә эше. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Хаталарны төзәтә белү. Үткән заман хикәя фигыльнең билгеле һәм билгесез төрләрен аера, җөмлә эчендә билгели белү. Мәгънә төсмерләренә төшенү (билгесезлек төсмере). Укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. | 29.09 | |
| 6 | Спряжение глаголов изъявительного наклонения в будущем определенном времени.<br><br>Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 14-16 нчы битләр: 1, 3 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең билгеле төрен аера, җөмлә эчендә билгели белү; мәгънә төсмерләренә төшенү. Г: билгеле киләчәк заман хикәя фигыль. | 6.10 | |

| № | Дәрес темасы | Уку-укыту эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| 7 | Спряжение глаголов изъявительного наклонения в будущем неопределенном времени.<br><br>Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | 14-16 нчы битләр: 1, 4 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Билгеле һәм билгесе киләчәк заман хикәя фигыльләрнең төрләрен аера, җөмлә эчендә билгели белү; мәгънә төсмерләренә төшенү (билгесезлек, икеләнү төсмере). Г: билгесез киләчәк заман хикәя фигыль. | 13.10 | |
| 8 | Образование деепричастия.<br><br>Хәл фигыльнең ясалышы. | 16-17 нче бит: 1-2 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Хәл фигыльнең төрләрен, аларның ясалышын гамәли үзләштерү. | 20.10 | |
| 9 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Успею ещё”.<br><br>“Өлгерәм әле” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | 18-19 нчы битләр: 5-13 нче күнегү. Хикәя уку, эчтәлекне аңлау, сүзлек өстендә эш, тәрҗемә эше, дөрес уку һәм әйтү. Хикәя фигыльләрне табу һәм язу. Җөмләләр төзү, яңа ситуация өчен үзгәртү. Логик чылбыр төзү. Диалог төзү. | Тексттагы лексик-грамматик материалны истә калдыру. Текстны аңлап уку, кирәкле мәгълүматны таба белү. Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү. Хикәядәге геройларга киңәшләр бирә белү. Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. Тексттагы тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү. Л: яраткан аш, аннары (аннан соң), караңгы төшкәч, өлгерәм, күзләр йомыла. Г: Хикәя фигыльнең заман формалары. Хәл фигыль. | 27.10 | |
| 10 | Условное наклонение, спряжение условного наклонения.<br><br>Шарт фигыль, шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 19-20 нче бит: 1, 3 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. Таблица белән эшләү. Тәрҗемә эше. | Шарт фигыльле җөмләләрне аңлап укырга, охшаш җөмләләр төзергә өйрәнү; рус телендәге кулланылышы белән чагыштырып өйрәнү; диалогик сөйләмдә куллану. Тиешле мәгълүматны табу өчен өстәмә чыганакларны куллану. Г: шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 10.11 | |
| 11 | Инфинитив. Инфинитив + модальные слова.<br><br>Инфинитив. Инфинитив+ модаль сүзләр. | 21-22 нче бит: 1-5 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. Тәрҗемә эше, җөмлә төзү. Логик рәт белән эшләү, логик парларны табу. | Җөмлә төзелешендә фигыльнең инфинитив формасын дөрес куллану; рус телендәге кулланылышы белән чагыштырырга өйрәнү. Л: зыян, мәзәк, ризык, кучерә, сөйли чакыра. Г: инфини-тив+модаль сүзләр; хикәя фигыльнең заман формалары; хәл фигыль. | 17.11 | |
| 12 | Лексико-грамматический материал в рассказе “Успею ещё...”(вторая часть). | 23-26 нчы бит: 1-11 нче күнегү. Хикәяне уку, сүзлек өстендә эш. | Тексттагы грамматик материалны истә калдыру. Текстны аңлап уку, кирәкле мәгълүматны | 24.11 | |

| № | Дәрес темасы | Уку-укыту эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| | “Өлгерәм әле...” хикәясендәге лексик-грамматик материал (икенче өлеш). | Тәрҗемә итү. Эчтәлек буенча күнегүләр эшләү. Сорау җөмләләр төзү. Диалог төзү. 3 нче зат исеменнән сөйләү. Хикәя героена таблица материалын кулланып характеристика язу. | таба белү. Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү. Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. Тексттагы тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү. Г: өйрәнелгән фигыль формалары. | | |
| 13 | Лексико-грамматический материал в стихотворении “Барый смотрит телевизор”.<br><br>“Барый телевизор карый” шигырендәге лексик- грамматик материал. | 27 нче бит: 13 нче күнегү. Уку, тәрҗемә итү, сүзлек өстендә эшләү. Сәнгатьле уку. Шигырьнең эчтәлеген бер-берең сөйләү. В.Нуриевның ”Өлгерәм әле...” хикәясен Р.Вәлиеваның “Барый телевизор карый” шигырендәге герой белән чагыштыру. | Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү. Чагыштырып сөйли белү. Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. Текстлардагы тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү. | 1.12 | |
| 14 | Выполнение упражнений по теме “Кто много читает, тот много знает”.<br><br>“Күп укыган күп белер” темасы буенча күнегүләр эшләү. | 28-29 нчы биттәге материал белән эшләү. Төркемнәрдә эшләү. Сорау җөмләләр төзү. | Өйрәнелгән темалар буенча актив сүзләрне, грамматик конструкцияләрне дөрес куллана белү. | 8.12 | |
| 15 | Окончания образующие прилагательные.<br><br>Сыйфат ясагыч кушымчалар. | 30-31 нче бит: 1-4 нче күнегү. Хаталар өстендә эшләү. Транскрипция билгеләре белән язу. Дөрес уку. Тәрҗемә итү. Бирелгән үрнәк буенча яңа сүзләр ясау. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. Л: берәүләр, оялу, кайбер, киресенчә, тупас, аралашу, фикер, килешәм, килешмим, дуслашу, ябык, рәнҗү, таза, искечә. Г: -лы/-ле, -сыз/-сез – сыйфат ясагыч кушымчалар. | 15.12 | |
| 16 | Антонимы. Использование их в речи.<br><br>Антонимнар. Аларның сөйләмдә кулланылышы. | 30-31 нче бит: 6-8 нче күнегү. Сүзләрнең антоним парларын табу. Сыйфатлар белән җөмләләр төзү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Антонимнарны сөйләмгә кертү. Г: антонимнар. | 22.12 | |
| 17 | Отрицательная форма условного наклонения.<br><br>Шарт фигыльнең юклык формасы. | 32-33 нче бит: 9-12 нче күнегү. Диалог төзү. Төркемнәрдә эшләү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Г: шарт фигыльнең барлык һәм юклык формасы. | 12.01 | |
| 18 | Вводные слова. Лексико-грамматический материал в тексте | 33-34 нче бит: 1-6 нчы күнегү. Җөмләләр төзү. Уку. Сүзлек өс- | Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү. | 19.01 | |

| № | Дәрес темасы | Уку-укыту эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| | “Секреты общения”.<br><br>“Аралашу серләре” текстына караган лексик-грамматик материал.<br>Кереш сүзләр. | тендә эшләү. Тәрҗемә итү. Аралашу серләре турында төркемнәрдә фикер алышу. Яңа исемнәр ясау. | “Аралашу серләре” текстына караган лексик-грамматик материалны истә калдыру. Фикер алышуда катнашу. | | |
| 19 | Лексический материал в тексте “Правила воспитанности”.<br><br>“Әдәп кагыйдәләре” текстына караган лексик материал. | 35-37 нче бит: 1-14 нче күнегү. “Әдәп кагыйдәләре” текстына караган лексик-грамматик материал буенча эш. Транскрипция билгеләре белән язу. Тәрҗемә итү. Сүзләрнең дөрес язылышы буенча эшләү. Фигыльләрне юклык формасына куеп язу. Монологик сөйләм оештыру. Төркемнәрдә фикерләшү. Диалог төзү. | “Әдәп кагыйдәләре” текстына караган лексик-грамматик материалны истә калдыру. Текстны аңлап уку, китерелгән фикерләр белән килешүеңне яисә килешмәвеңне әйтә һәм дәлилли бе-лү, киңәшләр бирү. Л: кагыйдә, таныш, игътибар, һаман, канәгать, гаеп, мәгънә, үз-үзен тота белә (белми). Г: шарт фигыль+модаль сүзләр. | 26.01 | |
| 20 | Имя действия. Отрицательная и положительная форма имени действия.<br><br>Исем фигыль. Исем фигыльнең барлык һәм юклык формасы. | 37-38 нче бит: 1-4 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. Сүзтезмәләр ясау, җөмлә төзү. | Г: исем фигыльнең барлык һәм юклык формасы. | 2.02 | |
| 21 | Лексический материал в тексте “Советы психолога”. С чего начинается воспитанность?<br><br>“Психолог киңәшләре” текстына караган лексик материал. Әхлак нәрсәдән башлана? | 38-39 нчы бит: 7-9 нчы күнегү. Уку. Тәрҗемә, сүзлек өстендә эш. Төркемнәрдә эшләү. Сорауларга җавап бирү. | Текстны аңлап уку. Өйрәнелгән лексик-грамматик материалны кулланып, әдәпле сөйләшү турында куелган сорауларга җавап бирә алу. Л: аралашу, аралашучан, ялгышны (хатаны) тану, ялгыш адым, кимчелекне төзәтү, бәяләргә, әңгәмәдәш, әһәмиятле, иркен тоту, уртак тел табу, мөнәсәбәт. | 9.02 | |
| 22 | Причастие. Повторение.<br><br>Сыйфат фигыль. Кабатлау. | 42-43 нче бит: 1-7 нче күнегү. Таблица белән эшләү. Җөмләләр төзү. Диалог төзү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Г: сыйфат фигыль. | 16.02 | |
| 23 | Лексический материал в рассказе “Хотел победить”.<br><br>“Җиңәсем килде” хикәясендәге лексик материал. | 43-45 нче бит: 1-5 нче күнегү. Уку, сәнгатьле уку, тәрҗемә итү, сүзлек өстендә эш. | Хикәяне аңлап уку. Хикәя эчтәлегенә караган сүзләрнең тәрҗемәсен белү. Шахмат уенын яратканыңны, шахмат түгәрәгенә язылырга те-ләвеңне әйтә белү. Л: шахмат түгәрәге, һәвәс-кәр, җиңү, җиңелү,оялу, кызару. | 23.02 | |

| № | Дәрес темасы | Уку-укыту эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| | | | | | |
| 24 | Настоящее время причастия.<br><br>Хәзерге заман сыйфат фигыль формасы. | 43 нче бит: 1, 6-7 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. Җөмләләр төзү. Монологик сөйләм оештыру. | Г: хәзерге заман сыйфат фигыль формасы. | 2.03 | |
| 25 | Прошедшее время причастия.<br><br>Үткән заман сыйфат фигыль. | 43 нче бит: 1 нче күнегү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Г: үткән заман сыйфат фигыль. | 9.03 | |
| 26 | Заккрепление временных форм причастия.<br><br>Сыйфат фигыльнең заман формаларын ныгыту. | Ишетеп аңлау күнегүләре. Диалог, монолог төзү. | Г: сыйфат фигыльнең заман формалары. | 16.03 | |
| 27 | Словосочетание “Прилагательное +существительное”. Лексический материал в тексте “ Какая нам девушка нужна?”<br><br>“Сыйфат + исем” төзелмәсе. “Ал кирәк, гөл кирәк, безгә нинди кыз кирәк?” текстындагы лексик материал. | 47-48 нче биттәге материал белән эшләү. “Сыйфат + исем” төзелмәсенә туры килүче сүзтезмәләрне язып алу. Транскрипция билгеләре белән язу. Хат уку, тәрҗемә итү, сүзлек өстендә эшләү. Фикер әйтү. Эчтәлекне аңлау. | Текст эчтәлегенә караган сүзләрнең тәрҗемәсен, дөрес язылышын, әйтелешен белү. Текстны аңлап уку. Л: тырыш, уңган, тыйнак, саф күңел-ле, чибәр, ямьле, тәмле телле, сөйкемле, тормыш, ризык, оекбаш, ямьләнә, яктыра. Г: “сый-фат + исем” төзелмәсе. | 23.03 | |
| 28 | Какие нам нужны девушки?<br><br>Безгә нинди кызлар кирәк? | 48 нче бит: 5-7 нче күнегүләр. Җөмләләр төзү. Аергычларны та-бу һәм шартлы билгеләр белән тамгалау. | “Ал кирәк, гөл кирәк, безгә нинди кыз кирәк?” тексты герое әйткән фикерләр белән килешүенне яисә килешмәвенне әйтә алу. Г: “сыйфат + исем” төзелмәсе. Өй сочинениесе яза белү. | 6.04 | |
| 29 | Какие наши друзья?<br><br>Безнең дуслар нинди? | 48 нче бит: 8-9 нчы күнегүләр. Фикерләрне дөрес язу. Диалог төзү. | Дус кызлар (егетләр), апа-абыйларның тышкы кыяфәтләрен, аларга ничә яшьикәнен әйтә, характер сыйфатларын сурәтли белү. Г: “сыйфат + исем” төзелмәсе. | 13.04 | |
| 30 | Местоимения.<br><br>Алмашлыклар. | 49-50 нче битттәге материал буенча эш: 1-2 нче күнегү. Таблицаны үзлектән өйрәнү, шуның буенча сөйләү. Алмашлыкларны тәрҗемә итү. Сүзлекләр белән эшләү. Төркемчәсен билгеләү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Г: алмашлыкларның төркемчәләре, зат, күрсәтү,сорау, билгесезлек алмашлыклары. | 20.04 | |

| № | Дәрес темасы | Уку-укыту эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| | | | | | |
| 31 | Определительные местоимения.<br><br>Билгеләү алмашлыклары. | 50-51 нче бит: 3-9 нчы күнегү. Җөмләләр төзү. Сүзлекләр белән эшләү. Тәрҗемә итү. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Билгеләү алмашлыкларын тану, тәрҗемәләрен һәм ике телдә дә кулланылыш үзенчәлекләрен белү, сөйләмдә дөрес куллану. Г: билгеләү алмашлыклары. | 27.04 | |
| 32 | Лексико-грамматический материал в тексте “Мой цвет зеленый. А твой?”. Какой мне цвет нравится?<br><br>“Минем төс – яшел. Ә синеке?” текстындагы лексик-грамматик материал. Миңа нинди төс ошый? | 51-52 нче бит: 10-11 нче күнегү. Дөрес уку, сүзлек өстендә эшләү. Тәрҗемә итү. Моногик сөйләм оештыру: үзеңә ошаган өлешне сөйләү. | Текст эчтәлегенә караган сүзләрнең тәрҗемәсен, дөрес язылышын, әйтелешен белү. Текстны аңлап уку, үзеңә ошаган өлешне сөйләргә өйрә-нү. Л: төс, яраткан төс, үз итә, бизәк, чалбар, каеш, өр-яңа, игътибар үзәге, күңелне күтәрә, ышанычны арттыра. | 4.05 | |
| 33 | Составные глаголы.<br><br>Тезмә фигыльләр. | 52-53 нче битләр: 13-15 нче күне-гүләр. Җөмләләр төзү. Диалог төзү, әңгәмә оештыру. Ишетеп аңлау күнегүләре. | Төсләрнең кәефкә ничек тәэсир итүе турында сөйләшүдә катнашу. Л: үз итә, күңелне күтәрә, ышанычны арттыра. | 11.05 | |
| 34 | Текст “В мире музыки”.<br><br>“Музыка дөньясында” тексты.. | 53-54 нче бит: 1-5 нче күнегү. Текстны уку, тәрҗемә итү, сүзлек өстендә эшләү. Җөмләләр төзү. Моногик сөйләм оештыру. | Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлау. Тексттагы мәгълүматка карата үз фикереңне әйтә алу. | 18.05 | |
| 35 | “Что такое природа?”. Лексика по теме “Природа”.<br>“Нәрсә ул табигать?” “Табигать” темасына караган лексика. | 58-59 нчы битләр: 1-3 нче күнегүләр. Дөрес уку. Тәрҗемә итү. Рәсемнәр буенча эшләү. Җөмләләр төзү. | “Табигать” темасына караган сүзләрнең тәрҗемәләрен, дөрес язылышын, әйтелешен белү. Нәрсә ул табигать дигән сорауга фикер йөртеп җавап бирә белү. Л: терлек, казылма байлык-лар, буыннар, кайгыртырга, сакларга, пычрат-маска, файдалы, Җир шары, гасыр, кими, бу-рыч. | 25.05 | |

## Эш программасына төзәтмәләр кертү бите

| Класс | Дәрес темасы | План буенча үткәрү вакыты | Төзәтмәләр кертүнең сәбәбе | Төзәтмәләр кертү чаралары | Фактта үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |